# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Конституциясенең 111 статьясына үзгәреш һәм өстәмә кертү турында**

Әлеге Закон шәхеснең, җәмгыятьнең һәм дәүләтнең, Татарстан Республикасы суверенитетының иминлеген комплекслы тәэмин итү максатларында кабул ителә.

1 статья. Татарстан Республикасы Конституциясенең 111 статьясына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 9-10; 1994, № 11; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1995, № 2-3, № 12; 1996, № 11) түбәндәге үзгәрешне һәм өстәмәне кертергә:

1. 111 статьяга түбәндәге эчтәлекле 18 нче яңа пункт өстәргә:

"18) Татарстан Республикасының Иминлек Советын төзи һәм аңа житәкчелек итә, аның статусы Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә".

2. 111 статьяның 18 пунктын 19 пункт дип санарга.

2 статья. Әлеге Законны матбугатта басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1999 елның 26 мае
№ 2180